# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Каразирек авыл җирлеге составына керүче Иске Каразирек торак пунктында 2020 елда гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«10» ноябрь 2020 ел № 1

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»ГЫ 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, 2020 елның 20 ноябрендә узган гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «2021 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Иске Каразирек авыл җирлеге составына керүче Иске Каразирек торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән , көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш, һәр балигъ булган кешедән 400 (дүрт йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм аны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә сез ризамы:

- Зират коймаларын урнаштыру (материаллар сатып алу)»

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 351 кеше кергән, аларның тавыш бирүдә 185 кеше катнашкан, бу 52,7% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

- «ӘЙЕ» позициясе өчен җыенда 185 кеше тавыш бирде;
- «ЮК» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены түбәндәге карар кабул итте:

1.Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Иске Каразирек авыл җирлегенең Иске Каразирек торак пунктында халык җыенын узды дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә дип танырга.

2. Ютазы муниципаль районы Иске Каразирек авыл җирлегенә керүче Яңа Каразирек торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, Россия Федерациясенең Кораллы көч сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш, 400 (дүрт йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм аларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме?:

- Зират коймаларын урнаштыру (материаллар сатып алу)"- буенча сорауны кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының "Иске Каразирек авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга мөмкин: http://jutaza.tatarstan.ru.

4. Әлеге карар рәсми халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Ютазы муниципал районы
Иске Каразирек авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Вәлиев